**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябрь, 2025 ел № 777-п

2026 елга Питрәч муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы карары, туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культура юнәлешендәге һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга расларга:

Питрәч муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата 0,9 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Питрәч муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында «http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А. Харитоновага йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды
«__» _______ 20 __ № ____

# Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының күп профильле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында программаларны гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елга сумнар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 441 | 17 142 | 20 490 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 9 941 | 17 642 | 20 990 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 341 | 17 042 | 20 390 |
| Табигать белеме | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |